**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«05» июнь 2024 ел № 48/1

«Новотроицк авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 октябрендәге 25/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы Хөкүмәт Карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Новотроицк авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 октябрендәге 25/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.7 пункты 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары, яр буйлары), гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек коммерциясез берләшмәләре урнашкан территорияләр).»;

1.2. 1 кушымтаның 1 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Д.М. Габделхаева